**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авыл торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

2020 елның 19 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән ,уку йортларына йөреп көндезге бүлектәукучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Зират янында контейнер мәйданчыгы төзү, контейнерлар сатып алу.
2. Контейнер мәйданчыгына юлга вак таш сатып алу.
3. Г. Тукай урамын яктыртуны реконструкцияләү
4. Өлешчә су белән тәэмин итү.
5. Кышкы чорда урамнарны кардан чистарту.
6. Музыка аппаратурасы сатып алу.
7.Янгын сүндерү өчен янгын колонкасы һәм янгын җиң сызганычлары сатып алу

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 377 кеше кертелде, тавыш бирүдә 263 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 263 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авыл торак пунктында гражданнар җыеннарын булды дип, гражданнар җыеннары нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлеге составына керүче Ямаш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешесеннән,уку йортларына йөреп көндезге бүлектә укучы студентлардан гайре, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Зират янында контейнер мәйданчыгы төзү, контейнерлар сатып алу.
2. Контейнер мәйданчыгына юлга вак таш сатып алу.
3. Г. Тукай урамын яктыртуны реконструкцияләү

4. Өлешчә су белән тәэмин итү.

5. Кышкы чорда урамнарны кардан чистарту.

6. Музыка аппаратурасы сатып алу.

7.Янгын сүндерү өчен янгын колонкасы һәм янгын җиң сызганычлары сатып алу

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт; Ямаш авылы, Х.Такташ урамы, 3в йорт; һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов